РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» июль 2021 ел г. Альметьевск № 1070

Әлмәт муниципаль районы ихтыяҗлары
өчен товарлар кайтару, эшләр башкару,
хезмәтләр күрсәтү предметы булган
муниципаль контрактларга банк хезмәте
күрсәтү очракларын билгеләү турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясындагы 2 өлеше нигезендә (алга таба - контракт системасы турында Закон), Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Контрактларга банк хезмәте күрсәтү турында» 2014 елның 20 сентябрендәге 963 номерлы карары,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы ихтыяҗлары өчен товарлар кайтару, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү предметы булган муниципаль контрактларга банк хезмәте күрсәтү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Контрактларга банк хезмәте күрсәтү турында» 2014 елның 20 сентябрендәге 963 номерлы карары нигезендә расланган контрактларга банк хезмәте күрсәтү кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә:

1.1. контрактны банк хезмәте күрсәтүгә карата, контрактның башлангыч (максималь) бәясе, контрактның бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән контракт бәясе кимендә 200 млн. сум булса, контрактны үтәү кысаларында исәп-хисапны мониторинглау банк тарафыннан уздыру;

1.2. күрсәтелгән контрактны үтәү кысаларында башкарыла торган исәп-хисап мониторингын үткәрүгә өстәмәләр кертүне күздә тоткан контрактны банк хезмәте күрсәтүгә карата, кабул ителә торган товарларның, эшләрнең (аларның нәтиҗәләренең),контракт шартларына (киңәйтелгән банк тәэмин ителешенә) туры килүен тәэмин итә торган башка хезмәтләр күрсәтүгә карата контракт шартлары, әгәр контрактның башлангыч (максималь) бәясе бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән контрактның бәясе кимендә 1 млрд. сум тәшкил итсә.

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU.) урнаштырырга.

Зак. № 305-2000

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов